| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» 03 2025 ел № 104

Балтач муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурс резервлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Балтач районы прокуратурасының 2025 елның 13февралендәге 02-08-01-2025/прдп82-25-20920011 номерлы «16.07.2022 №217 карарга» протесты нигезендә, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 16 июлендәге 217 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурс резервлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

« - кешеләрнең гомере һәм сәламәтлеге өчен турыдан - туры куркыныч тудырган гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр, зыян күргән гражданнарны вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктларын булдыру һәм карап тоту өчен, халыкка бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү өчен, шулай ук зыян күргән халыкның тормыш эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле башка беренчел чаралар өчен.

Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурс резервлары, дәүләт матди резервыннан тыш, югары әзерлек режимы кертелгәндә файдаланылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты житәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Житәкче А.Ф.Хәйретдинов